РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Простинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района
423553, Нижнекамский район,
с. Прости, ул. Школьная, 8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Прости авыл җирлеге
Советы
423553, Түбән Кама районы,
Прости авылы, Мәктәп урамы, 8

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www.prostinskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

14.11.2023 ел № 18

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 2011 елның 17 октябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең нотариат турында законнары нигезләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 һәм 20 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Прости авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 2011 елның 17 октябрендәге 12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Прости авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының түбәндәге нотариаль гамәлләр башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашуын билгеләргә:

1) көчемсез милек белән идарә итүгә ышаныч кәгазьләреннән тыш, ышаныч кәгазьләрен раслау;

2) мирас милке исемлеген төзү юлы белән мирас милкен саклау буенча чаралар күрү;

3) документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау;

4) документлардагы имзаның чынлыгын раслау;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, затлар турында мәгълүматны раслау;

6) гражданның исән булуын раслау;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз куллары белән куйган имзасының үз имзасын факсимиль кабатлавы белән бер үк булуын раслау;

8) гражданның билгеле бер урында булуын раслау;

9) фотода сурәтләнгән кеше белән гражданның бер үк булуын раслау;

10) документларны күрсәтү вакытын раслау;

11) электрон документның кәгазь чыганактагы документка тиңлеген раслау;

12) кәгазь чыганактагы документның электрон документка тиңлеген раслау;

13) нотариаль рәвештә расланган алыш-бирешләрнең эчтәлеген белдерүче документларның дубликатларын бирү.».

2. Әлеге карарны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Простинского сельского поселения

Д.А. Бәдәртинов